Д. Г. Саврушевский.

САНДУГАЧ.

СТИХОТВОРЕНИЯ

НА КРЯШЕНСКОМ ЯЗЫКЕ

КАЗАНЬ.
Третья Государственная Типография.
1920.

Список

стихотворений, вошедших в сборник
Д. Г. Саврушевского.

---

1. Сандугач—соловей.
2. Жаз башы—начало весны.
3. Май айы—месяц май.
4. Ӓдям уйы—мысль человеческая.
5. Дӧнья жӧзӧ—лицо вселенной.
6. Сад бакчасы—сад.
7. Алма агачы—яблоня.
8. Ана жӧряге—материн. сердце.
9. Бишек жырыуы—колыб. песня.
10. Тямяке—табак.
11. Эчкелек—пьянство.
12. Жярминкя—ярмарка.
13. Сыйыр—корова.
14. Алтын кюкяй—золот. яичко.
15. Алтын балык—золот. рыбка.
16. Куян жорто—зайкина избушка.
17. Ат—лошадь.

18. Кязя—коза.

19. Тычкан—мышка.

20. Оло тилеляр—большие дураки.

21. Дунгыз—свинья.

22. Эттян сӧяк артмас—собака от мосла не откажется.

23. Сугыш халляре—военные события.

САНДУГАЧ.

Сайра, сайра, сандугач,
Карлар китеб жаз булгач,
Агач-ўлям жяшяреб,
Жирнен жӧзӧ жаңаргач.

Кюб кешеляр тыңныйлар,—
Сайра, сайра, чутылдат;
Ачыулыны сюрелдер,
Моңайганны тиз жыуат.

Бигюк матур сайрыйсың,
Нейляр уйлаб жырлыйсың,
Кӧйнӧ каян табасың,—
Жӧз тӧрлӧгя борасың?

Бютян кошлар алайук
Сайрамыйлар синең кюк:
Сайраб-сайраб карыйлар,
Синең кюгюк булмыйлар.

Гяўдяң начар булса да,
Синең таудыш бик чиста,
Тӧсӧң соро булса да,
Сайрарга син бик оста.

Ичтя тыңнаб туймыйым
Сайрауыңны, сандугач,
Сине кӧн дя тыңныйым,
Эшляремнян туктагач.

Сине бер-аз тынгнасам,
Кюнгелляреи жыуана.
Ангный белгян кешеляр
Бар да синга кыуана.

Сайра, сайра, сандугач,
Жиргя кюммя талантынг,
Сайра халенг бар чакта,—
Кюб жук сайрар багытынг...

Жаз башы.

Февраль беткячь кыш ўтя,
Март айында жаз житя:
Кояш жакшук кыздыра,
Карны бер-аз сыздыра.

Каралдырар ӧстӧннян
Тамчылар да тамалар;
Мартнын уи бишляренняп
Герляўекляр агалар.

Бала-чага, сӧйӧнӧб,
Кӧряк тотоб жӧрӧйляр,—
Герляўек шяб китсеч диб,
Канауларны кӧрӧйляр

Уй-сыуырак жирляргя
Сыу кюл булыб жыйыла.
Каз-ўрдякляр тансыкка
Чап-чяц сыуга койона.

Жул бсляре гел тирес,—
Кара жылан кюк жата
Кичкя таба, жебшеткяч,
Ат аягы бик бата.

Мал терлек тя, кош-корт та
Жаз житкянне сизяляр:
Чӧкӧрдяшеб, сайрашыб
Ояларын тибяляр.

Март числасы бетяряк
Чыйыршыклар кюреня;
Алар сайрый башлагач,
Кыш ўткяне беленя.

Апрель айы башында
Кар сыулары кузгала;
Тагы беряр атнадан
Икешлярдян боз ага.

Бу багытта кешеляр
Чаналарны жыялар:
Жазгы кӧнняр житеўгя
Арба кӧйляб куялар.

Корт асраган бабайлар
Умарталар чыгара,
Делянкеле агайлар
Урман эше кубара

атын-кызлар шак та-жок
Барда киндер сугалар;
Кичкя таба, аш эчкяч,
Сыу жарына баралар.

Жаңа чыккан чирямдя
Ташыу караб торалар,
Тӧрлӧ уйыннар уйныйлар,
Тӧрлӧ кинјяш коралар.

Май айында.

Май айынын башында
Агач-ӳлям уяна,
Тагы беряр ӓтнадан
Бӧтӧн дӧнья кыуана:

Кортлар оча сӧйӧнӧб,
Табыш ала тырышыб,
Умартӓсы жанында
Жата талга сырыщыб;

Агач-ӳлям ӳңгяря—
Жяшел кейем кейеня,
Кар эрегян жирлярдя
Сары чячяк кюреня.

Кюгярченняр гöрлöйляр,
Кюбялякляр уйныйлар,
Тургайлар да ауада
Чеңгердяшеб жырлыйлар.

Кичке салкын тöшкячтен,
Сандугачлар сайрыйлар.
Кюб кешеляр аларны
Кюңел салыб тыңныйлар.

Ул кöнлярдя мужиклар
Сабан-ашлык чячяляр,
Иртюк тороб чяй эчкяч
Бер да кырга китяляр.

Сабан чячеб бетергяч,
Тирес тюгя башлыйлар,
Кюңел биреб эшлягяч,
Аш жаратыб ашыйлар.

Сыу буйында балалар
Каз бябкясе саклыйлар,
Эш аралый ÿзляре
„Таш чюблямеш“ уйныйлар.

Кай чагында, талыгыб,
Жаталар да жоклойлар,
Ул арада каргалар
Бябкялярне жолкойлар.

Май айынын башында
Карт кеше дя жяшяря:

Кыш бойоккан кюнгелне
Жылы кӧнняр кютяря;

Бар бабайлар, ӓбейляр
Пич башыннан тошяляр,
Бик кюб эшляр эшлейляр,
Кояшка да п-ешяляр.

Эй матур жаз кӧнняре,
Сезне кемняр жаратмас?
Балкыб торган жылы кӧн
Кемнен жанын жыуатмас?

Ӓдям уйы.

Дӧньядяге бар нястядян
Алдымырак, жугары
Ӓдям уйы, ӓдям сюзе,
Уйыннары, жырлары.

Жирдян жӧрӧй, сыудан жӧзя,
Кюктян оча, гел кош кюк;
Ул чыгарган жактырткычлар
Утсыз жапа, кояш кюк.

Тауны казый, ташны кися
Кулындагы коралы;

Алтмыш катлы пулат сала
Аннын алтын куллары.
Илдян илгя кючеб жөрөй
Ул төзягян жырыулар,
Сандугач кюк сайрашалар
Ул жасаган уйыннар.
Мең-мең жыллаб үлмей төра
Анын жазган сюзляре,
Мең жыл элек белеб тора
Анын кюңел кюзляре.
Тик ӓдямдя кай чагында
Карангылый акылын:
Гаделлекне жиргя табтаб,
Дошман кюря жакынын.

ДӦНЬЯ ЖӦЗӦ.

Исяблясям исем китя
Тормош законнарына,
Кюргян сайын хайран булам
Дөнья матурлыгына.
Ней ололок, ней матурлык,
Көндөз аяз булганда,

Нурлы кояш жактысына
Дӧнья балкыб торганда!

Бу нейлектян, кюбтяниянме
Кояш былай жактырга
Ней сябябтян жылысы да
Бӧтӧн жирне жылыта?..

Ней ололок, ней матурлык
Аяз тӧнняр булганда,
Алля ничя мен жондозлар
Жем-жем итеб торганда!

Тулган айнын жактысы да
Бу турлардан уйлата.
Уй ӧстӧня уй тӧшӧря.
Сӧйӧндӧря, монгайта.

Кышкы кӧннӧ карлар жауа.
Сыуык була, тунгдыра,
Жяйге кӧннӧ жангыр жауа,
Ашлык жимеш унгдыра.

Басыуларга чыгыб жӧрсянг,
Ашлык ускян чагында,
Бик кюб габрят син аласынг
Уз кюзенгнен алдында.

Ничя тӧрлӧ ашлык-ӳлям
Башын жилгя эяляр,
Ничя тӧрлӧ кош-корт жӧрӧй,
Очоб кюккя меняляр;

Кортлар бежляб бал жыялар,
Тургайлар да сайрыйлар,
Ар кайсысы ўз ўзенчя
Кюнел биреб жырлыйлар!..

Белемнектян карасан да
Кюб кодрятляр кюрясен.
Кайсын-берсен, кюрмясян.
Уйлаб бар диб белясен.

Микроскоплар кюрсятляр
Кюз кюрмяслек микроблар,
Дингезлярне жарыб жӧрӧй

Тау кадяре зур китлар.
Жир ҙӧзӧня кюз салсан да,
Ис китярлек эшляр бар:
Жирляр, сылар, ташлар, таулар,
Тӧбсӧз-тирян тӧшляр бар..

Ней сябябтян, кюбтяннян ме.
Дӧньябезнын булыуы,
Ауадагы пястялярнен
Рятен бозмой тороуы?..

Бу турлардан уйга тӧшсям,
Куркыб, калтраб китямен,
Кай чагында, уйлый-уйлый,
Тирляб, пешеб бетямен.

Исяблясем исем китя
Тормош законнарына,
Кюргян сайын хайран булам
Дőнья матурлыгына!..

САД БАКЧАСЫ.

Эй жяшел сад бакчасы,
Бик жаратам мин синет
Атам, анам шикелле
Туйдырасын син мине.

Ней файдалар китеря
Синдя булган жимешляр,
Зур исябляр тőшкяндя,
Син бирясен кингяшляр.

Агач чячяк атканда,
Кортлар оча сőйőнőб,
Син жатасын чирямдя,
Кюлягягя сыйыныб.

Кюб турлардан уйлыйсын,
Акрен геня жырлыйсын,

Бик кӧрсӧнӧб сулыйсың,
Кай чагында жылыйсың.

Эй жяшел сад бакчасы,
Жакты кояш жылысы,
Сандугачлар тауышы,
Уйлы жӧряк сулышы,

Онотмамын гумергя
Синдя кюргян кӧннярне,
Жяшняб ӱскян гӧллярне,
Ай жактылы тӧннярне.

Алма-агач.

I

Байтак жыллар элгяре
Бер оло жул ӧстӧндя
Баяр жорто бар ыйы
Бик зур садныӊ эчендя.

Сад бакчасы жыл сайын
Бик кюб жимеш китергян:
Эш сӧйӧучян хужасы
Сыуны бик нык сибтергян.

Тора-торгач бу жортны
Бурлар талаб жандырган,
Жяшняб торган жорт урын
Басыу итеб калдырган.

Сатында да жанмыйчы
Бер казык та калмаган,
Тик иг чиття, пишлябтер,
Бер алмасы жанмаган.

Шуннан ары хужасы
Читкя киткян торорга,
Бу кайгыны онотоб,
Жанга тормош корорга.

II

Эш бик начар алманын:
Жангыз башы, жамансы...
Уткян конгяр исендя:
Кайда микян хужасы?..

Жяйнен эссе кононде
Сыу сибеуче жук мынгар,
Жалан-жалан миндятя
Котоутяге мал тыуар:

Кай чагында, кич-иртя,
Карга куна башына,

Жилляр жарган сабына
Атлар килеб кашына;

Тюбяняряк ботакны
Кязя-сарык бетеря.—
Карар кеше булмагач,
Бар да зыян китеря.

Жаз башында, алайда,
Чячяк ата бу агач,
Тик чячяге äз була,
Бер кастяр дя булмагач.

Кöзгя таба, кай жылны,
Алмалар да кюреня,
Тик пешкенче тормойлар,—
Узган барган ӱреня.

Бар кеше дя агачны
Ачеалма диб беляляр,
Ашаб ашаб карагач,
Чырай сытыб кöляляр.

III

Тора-бара бу жиргя:
Жаңа хужа табыла:
Мал кöтöлгян басыуда
Тагы казык казыла;

Жанган жортлар урнына
Тагы зур жорт салалар.
Элекеге сад урнын
Ряшяткяляб алалар.
Алма агачы тагынук
Кастяр кюря хужадан
Котмягяндя котолды
Элекеге пужадан:
Тоòондяге балчыгы
Жомошатыб казылган,
Жирнен дымы бетмяскя,
Салам-тирес жабылган.
Оч дюрт конгя бер табкыр
Сыу сибяляр тооня,-
Шокор итя Аллага
Казер кюргян конOня,
Коз житяряк агачнын
Бик шяб кызыл алмасы
Озоб ашаб карагач,
Бик сойондо кужасы.

АНА ЖОРЯГЕ

Балакайым, голокяйем,
Жаным, жан кисякяйем,
Татлы жоком, ашамныгым,
Эчяр эчемнекяем,

Сӧйӧнӧчӧм, кӧйӧнӧчӧм,
Гумер кюргян кӧннярем
Синенг ӧчӧн жуйган кӧчӧм,
Жоком калган тӧннярем.
Синга бер-бер зыян кился,
Жя чир тейся тяненгя,
Ашау, эчеу иcкя килмей,
Жӧряк жылаб тибеня.
Синенг ӧчӧн, киряк булса,
Жаным жарыб бирермен,
Катяр чакка туры килсянг,
Утка, сыуга керермен.
Балакайым, ник бу кадяр
Жаратамын мин сине?
Син дя шулай, минем кюгюк,
Жаратасынг мы мине?
Тынгна, балам: гумеренгдя
Тырыш, сабыр, гадел бул;
Шул гаделлек исеменя
Жан бирергя ӓзер бул.
Балакайым, гӧлӧкяем,
Кайчан кеше булырсынг?
Исяннектя кюрем микян—
Кайда, ничек торорсонг?

Бишек жыруы.

Аллӧй, ӓллӧй, ӓллӧкӧй,
Жокоӈ киля бябекей.
Жокла, жокла, бябейем,
Кая битеӈ ӱбейем.

Шыгыр, шыгыр итядер,
Балам жоклаб китядер.
Жокла, жокла, бябекям
Жоклатадыр ӓнекяӈ.

Ник кӧлясеӈ, бябекям:
Ачуланыр ӓнекяӈ:
Тятят итяр ӱзеӈне,
Жом тизеряк кюзеӈне.

Жокла, жокла, жом кюзеӈ,
Жоклатамын мин ӱзем.
Эй бябейем, гӧлӧем,
Кая тагын ӱбейем.

Балакайым, жаныйым,
Сиӈа жыру жырлыйым,
Кюгярчен кюк гӧрлӧйӧм,
Жокла, жокла, гӧлӧйӧм.

Син жоклаган арада,
Эшем эшляб ташлармын:
Идян-сяке себереб,
Икмягемне басармын.

Шыгыр, шыгыр итядер,
Балам жоклаб китядер.
Аллой, äллöй, äллöкöй,
Жокладыңмы, бябекей?

Башың жанга боролдо,
Кюзляреӊ дя жомолдо.
Кая тагын ўбейем,
Тыныч жокла, гöлöйем.

ТЯМЯКЕ.

Нейляр кюрмей äдям башы
Жирдя гумер иткяндя...
Кюб чагында кайгы тöшя,
Сöйöнöчляр кöткяндя.

Кай чагында, эчеӊ пошоб,
Ней эшляргя белмейсеӊ,—
Бöтöн дöнья начар тея,
Жакшы нястя кюрмейсеӊ...

Жарый äле чыгарганнар
Тарта торган тямяке:
Бик жамансы булгандыр дим
Житмеш жыллаб элеке.

Зур кайгылы ӓдямне дя
Шул тямяке жыуата,
Ут кюк жанган жӧрякне дя
Бер папирос сыуыта.

Кай чагында, сакланмыйчы,
Цростудиться итярсең,
Самый киряк эш ӧстӧндя
Кинят чирляб китярсең:

Тартыб жибяр бер папирос,
Шушы сиңа килешер,
Тямякенен кыуатына
Нейдей чир дя бирешер.

Тямякенең никотины
Микробларны бетеря,
Шуңар кюря саулык ӧчӧн
Бик зур пайда китеря.

Килче, туган, тартыйыкчы,
Махорка бар ӓзеряк
Шырпың бар мы? Минем беткян.
Мя тот, жаса тизеряк!..

— Утырмачы эт кюк ӱртяб,
Бар чыгыб тарт, бар, бар, бар!
Дяшмей тартыу житмей ӓле,
Пайдасын да табканнар!..

Сез жауызлар, сез киафрлар,
Малдан хужы буласыз,—

Мал ашамас ӓче ўлямне
Аузыгызга аласыз.

Ашар микян, биреб кара
Бер-бер малга тямяке?
Ашау тўгўл, жакын килмяс.
Анын исюк ӓшяке.

Ич пайдасыз арыу нястя,
Тик саулыкны бетеря.
Жорт тотоуы турыннан да
Аз ме зыян китеря?

Жарый ӓле ўткян жылны
Байтак нястя чячтегез—
Сатыб алыб тарткан чакта
Ней акчалар тюктегез?

Шырпы, кыягаз алырга да
Икмяк тотоб чыгасыз,
Оялярда кюкяй калмый-
Барын шунда тыгасыз.

Ник бу кадяр белэмсез сез,
Нейгя қиряк ул тартыу?
Ней ӓйтясең, ней тиргейсең,
Кая сезне туктатыу!

Заман акры житяргя дер,
Тартмый торган кешюк жук,
Атсыз тунсыз жарлылар да
Тямякегя бар да тук.

Жяше тарта, карты тарта,
Тарта пубы, мулласы...
Алар иткян теляк-намаз
Ничек кабыл буласы?

Тэртыу гына житмей äле,
Боронга да иснейляр.
Берсен берсэ очраткэнда,
Тырыс какмый китмейляр.

Татар калкы, мосольманнар,
Тел астына салалар.
Мыны кюреб, кюб кешэляр
Шаклар катыб калалар.

Ней тяме жук, исе сасы...
Чыгардылар бер этлек...
Дяўлятенне тöтöн иткяч,
Ник жукармас тереклек?

Остял буйы, балалар да
Öйрянергя тырыша:
Аулак жиргя жыйылышыб,
Шырпы белян булыша.

Котом чыга уттан-кюздян,
Бер нястясез калыңсың,
Жортсыз-жирсез калыб китсяң,
Тагы ничек салырсың?..

Ис китмяслек тöгöл инде
Бу чактагы äдямгя.

Угет итеб әйткян сюзляр
Бар да китя әрямгя...
Жарый әле, катын-кызлар
Бу этлекка биренмей.
Берян-сярян бар барын да,
Бигюк кюзгя кюренмей.
Тора-бара, бер башланса,
Алары да өйрянер:
Заманасы шундый инде,
Усаллык тиз көйлянер...
Эштетямсең оло тиле?
Тартма димен, көйрятмя!
Син ичмаса үзең тартсаң
Жяш кешене өйрятмя!
Кемняр шулай җүнне кеше,
Өйдя тартыб утыра?!
Әбяү, киафр, оло тиле,
Торган сайын котора!
Әйтеб торам, көйрятмя диб
Аның сайын тартмакчы!
Бик әйткянне белмясягез,
Ана кисяу агачы!!.
Атаң-мярхум, бик эчся дя,
Тямякене тартмады,
Аның ише этлек өчөн
Жорт нястясе сатмады.

Ӱткян гумер жакшы булды,
Шӧкӧр итям Ходайга,
Арям-шярям итмягячтен
Корт барды гел унгайга.
Нейляр булыр сунгга таба,
Минем кюзем жомолгач?..
Кайтыб кюреб булмас инде,
Ӧскя балчык салынгач...
Ӱткярясеэ ӱзягемя,
Эй балалар, балалар!..
Айткянне дя белмейляр бит,
Жюнсез, жӧзӧ каралар!..

ЭЧКЕЛЕК.

Кызыл Микит эчеб жӧрӧй,
Бар дӧньясен онотоб,
Ишлегеня жамагатын
Кӧно-тӧнӧ жылатыб.

Атасыннан калган маллар
Гел ӓрямгя беттеляр;
Быйыл меня балалары
Мир кӧтӧӱе кӧттӧляр.

Ней мал ыйы Питер байда:
Ындыр тулук игене,
Ун биш башлаб ат сыйыры,
Жӧздян артык сарыгы.

Акчасы да кюб диделяр,—
Банкыда да булган дей.
Меня казяр Мекетясе
Калдык атын саткан дей.

Шулай, туган, дӧнья хале...
Уйлаб торсаң гыбрят кюб.
Эчкечӧнен кӧн тормошо
Жил сындырган салам кюк.

ЖЯРМИНКЯ.

Меня сиңа жярминкя
Кюзең туя караб кал,
Жан телягян тауар бар,—
Акчаң булса, сайлаб ал.

Тартма-тауар кюб икян,
Челтяр киряк буласы
Киряк тауар кюб кюбең,
Акча каян аласы?.,

Ибан сорой кюн итек,
Палук сорой мамык шял.
Ӱземя дя бик киряк...
Алмам инде, акча жял.

Ана кряшен кызлары
Чарт-чорт сагыз чяйнейляр,
Тӧрлӧ жактан жыйылыб,
Жукпы-барны сӧйлӧйляр.

Ӧс-башлары бик чиста,
Тюше тулы дяӱяте,—
Жалт-жолт итя кояшта
Ата-баба дяӱляте.

Кряшен жегетляре дя
Ӓрле-бирле жӧрӧйляр,
Узган-барган кызларга
Кюзне тӧшӧргялейляр

Кайсылары, жыйылыб,
Уйнаб-кӧлӧб торалар,
Тямяке дя тарталар
Айбагыр да жаралар.

Пинжак белян фуражкы
Кюбесенен ӧстӧндя:
Кара шляпя, казакый
Бетеб бара илендя

Ана кырык тартмачы
Шырый-шырый кычкыра.

Өч тянкялек тауары,
Жөз тянкялек ауазы:
,,Эй бабайлар, äбейляр,
Эй агайлар, тютейляр,
Бире таба килегез,
Тауарымны кюрегез!

Алчы сагыз, жä уймак
Алмый китмя, кюб уйлаб.
Иннек, кершян, жиз эскяк...
Килче тотчо, жяш жөряк"!..

Киля гармун тауышы
Кямитчеляр жагыннан.
Äлля тышка чыккаинар,
Калык бик кюб жыйылган?..

Кая мин дя барыйым,
Кямитлярен карыйым,
Жюлярлярен кюрейем,
Бер туйгынчы көлөйем.

Чыккан икян, кара äле,
Бейешяляр, уйныйлар.
Матур икян кызлары,
Чырылдашыб жырлыйлар.

Калпак кейгян жюляре
Тиле булыб көлдөря,
Үзе тиле булса да,
Акыллыны бөлдөря.

Көлдөря суң, алайда,
Бөтөн калык шау итя
Каян таба көлкө сюз,—
Ичтя жукны бар итя.

Умартада корт ничек,
Шулай шаулый жярминкя,
Ошатырсың, кюз жомсаң,
Кетеўдяге терлеккя.

Кайсы көля кычкырыб,
Жярминкяне жаңгырытб,
Жяш балалар жөрөйляр,
Таш сыбызгы сызгыртыб.

Атлар тора кешняшеб
Бер берсеня дяшешеб,
Кайсылары жир ыулый
Жукка жирсяб, тибешеб.

Сатыу, алыу, алдашыу,
Ачыуланыу, даулашыу,
Ирек ачыу, көлөшөў,
Жукны-барны сөйляшеў.

Сыйыр сыйы.

Шӧкӧр, уңдым сыйырдан.
Кысыр калмый... бик майлы...
Жя, кодача ашачы!
Шӧкӧр, тормош уңгайлы...

Атна сайын май жазам,—
Ӧзӧлмӧйӧм каймактан...
Жя, каймактан, ауыз ит!
Жаңа гына кайнаткан.

Балалар да, ӱзе дя
Катык-сӧтнӧ жарата,
Тик-кар беткян базымда,—
Сӧтӧм ӓчеб алжата.

Ашасана! —Ашыйым...
Эй матур суң кюлмягең!
Кайчан тектең кодача,
Бар ыйы мы кейгянең?

— Жаңа кюлмяк кючтиняч,
Ӓле жаңа кейеӱем:
Алыб кайтты Казаннан
Палук ире, кейяӱем.

Ашасана кодача,
Жя, жя, аша, тартылма!
Аштан ашка жӧрмягян,—
Кашык куйыб утырма!

— Бик ашыйым, кодача.
Ашар жирдя жук ыйы:
Жаңа гына чяй эчтек,
Тамагым бик тук ыйы.

Каймагың да, майың да.
Тямне тейгяч ашадым...
Але мин дя жаңарак
Каймак жыя башладым.

Сыйыр сыйы бар чакта
Кунак сыйлау кюңелле,
Чяйлек сӧт тя булмаса,
Бойоктора кюңелне...

— Ашасана!.. — Ашыйым.
Жя, жя, аша, тартылма,
Жалап-жалан килмейсең,
Кашык куйык утырма!..

Аля кызыл сыйыр да,
Ӱз уйымча, бызаулар
— Бирсен Алла!.. Эшчең бар:
Киленнярең сауарлар...

Эшеттең ме, кодача,
Нарат-Асты жанган дей?..
Ӧч жӧз жортло ауылдан
Бары биш жорт калган дей,

— Эй, кодача! Эшеттек,
Искеняйең китясе,

Ӧч-дюрт сагят эчендя
Бӧтӧн жортоң бетясе!
    Жяйге кӧнняр бик хатяр,
    Котом чыга жаныудан,
    Арыу гына торганда.
    Бер нястясез калыудан...
Ашасана, кодача,
Нек айткянне белмейсең?
Жя, жя, туйдыр тамакны,
Жалан-жалан килмейсең.
    — Бик ашадым, кодача,
    Алыбук куй майинны.
    Ашар жир дя жук ийи,
    Бик жараттым сыйыгны...

Алтын кюкяй.

    Бер ӑбейпен тауыгы
    Алтын кюкяй салган дей
    Ис китяргек зур эшке
    Бӧтӧн ауыл белгян дей.
Кӧндя сайын ул титей
Пич астында китаклый;
Анын салыб чыгыуын
Ӑбекясе ген саклый.

Пыялалы ышкапта
Жалт-жолт итя кюкяйляр
Шаклар катыб чыгалар
Мыны кюргян тутайлар.
Меня бердя бер табкыр
Килеб керя бер ӓбей;
Кюкяйлярне кюргячтен,
Кӧнчӧлӧктян былай дей:
„Ул тауыкнын бӧтӧнняй
Эчен алтын алгандыр!
Байырынга карышы
Бу кодрят эш булгандыр.
Миндя булса бу тауык,
Суяр ыйым мин аны,
Сатар ыйым тизеряк
Эчендяге алтынны.
Сибляр эйем ӧйӧмнӧ,
Тотар ыйым бакчамны,
Салыр ыйым банкыга
Аннан калган акчамны"...
Усал карчык кингяше
Тӧйӧл салды ӓбейгя:
Тиз б йысы бик киля,—
Чыдый алмый бу уйга.
Шул кӧн юк ул тауыкны
Бик жакшылаб туйдырды,
Аннан ары бер картка
Эжяллямей суйдырды.

Тауык әчен жарганда
Ӑбей дер-дер калтырый:
Бютякядя сары май
Алтын булыб жалтырый.
Ичтя кото калмады,
Майны кюреб сауытта,—
Жюляр ӑбей аıгнады
Алтын жугын тауыкта.

АЛТЫН БАЛЫК.

(По Пушкину).

I.

Кайчан исе бер заманда,
Оло диıгез буйында
Торган имеш бер карт бабай
Иске балчык ӧйӧндя.
Катыны да булган имеш—
Усал гына бер карчык:
Картын кӧндя тиргягян дей
Бик кычкырыб, бик жарсыб.
Бабай кӧндя балык тоткан,
Ӑбей орчок (ж) эрлягян.
Бабай балык ӓз китерся,
Ӑбей аны ӓрлягян.

II.

Меня бердя бер кӧннярдя
Бабай китте дингезгя.
Ӑбей калды мыж-мыж килеб
Ӑлля нейдей жук сюзгя.
Ул кӧннӧ жил бик шяб булган,—
Дингез каты шаулаган:
Бабай жукка кӧчӧн жуйган,—
Балык бердя калмаган.
Эш бабайнын начар булган,
Ӱзе бигюк талыккан;
Буш кул белян ӧйгя кайтса
Карчыгыннан курыккан.
Сала, сала аукн бабай,
Балык кермей тамчы да
Мескен чистый халдян тая,
Кул-аягы талчыга.
Калдык табкыр салган чакта,
Ауга керде бер майма.
Алтын майма булган дейляр—
Меня картка зур пайда.
Ич жук ыйы карт бабайнын
Алтын балык кюргяне,
Кюреў тӧгӧл булмаган дыр
Эшетеб тя белгяне.
Алтын балык бик тырпылдай
Аудан сыуга тӧшяргя,

Тик кӧчо жук, теш бялякяй
Ауны кисеб тишяргя.

Кулын сузыб тоткачкына,
Бабай кинят эшетте,—
Алтын балык гел кеше кюк
Меня нейдей сюз йитте:

„Эй кадерле, жакшы бабай,
Мин҃а рахим итсяня:
Ташла мине кире сыуга,
Сюзем тын҃ный кюрсяня“.

Зур кючтинач бирем син҃а,
Телян҃янен҃ алырсын҃;
Рахятлектя гумрен҃ ӱтяр,
Бик тизентен байырсын҃.

Кото чыкты карт бабайнын,
Кул-аяг҃ы каушады:
Бер нястя дя кирякмяс диб,
Ул балыкны ташлады.

Китте бабай ӧйгя кайтыб.
Балык анын уйында.—
Усал карчык жебен (ж)эрлей
Зимнянкясе буйында.

Бабай мын҃ар йитеб бирде
Алтын балык кергянен,
Аны сыуга жибяргянен,
Анын йиткян сюзлярен.

Бабай әйтеб биреў белян,
Әбей аңар тотонды.
Бабай-мескен башын кашый,
Әбей чистый которды:

„Тиле син, дей, ким акыллы,
Ник балыкны ташладың?
Ник ичмаса, бирям дигяч,
Кючтинячен алмадың!?

Бар тизеряк балыгыңа,
Сора жаңа тагарак:
Жарылган бу, бялякяй дя,—
Булсын мыннан олорак!“

Китте бабай сыу жарына,
Акрен геня кычкыра:
„Чыкчы мында, балыкай“, диб,
Ул балыкны чакыра.

Сыу тӧбӧннян алтын балык
Жалт-жолт итеб кюренде
Аны кюреб, карт бабабыз
Чын кюңелдян сӧйӧндӧ

Балык, жарга жакын килеб,
Бабай белян сӧйляште.
Ул бабайга бик ошады,
Әйткян сюзе килеште:

„Тагарагың жаңа булыр,
Бар кайт бабай ӧйӧңя“.

Шулай дигяч, алтын балык
Чумды диңгез тӧбӧня.
Ӧйгя таба китте бабай.
Бик ашыга кайтырга
Казер алган сӧйӧнӧчӧн
Карчыгына ӓйтергя.
Кайтса, карчык орчок (ж)эрлей,—
Жирдя жӓңга тагарак!
Узе чиста, ӱзе жиңел,
Искесеннян олорак.
Бабай мыңар бик сӧйӧндӧ,
Кӧлӧб карый карчыкка,
Алля ул да кӧлмясме дей,
Сӧйӧнӧчтян, тансыкка.
Кая кӧлӧӱ ул карчыкта,—
Жимерелеб утыра;
Бабай кӧлгяч, ачуланыб,
Тамак жарыб кычкыра:
Ник кӧлясең, тиле карт, дей,
Нейгя бигюк кыуандын?
Кюбме пайда тагарактан,
Ник жук нястя сорадын?
Бар тагы кит балыгыңа:
Сора жакшы, жаңа жорт,—
Зимнянкябез искергян бит...
Кыйыу сора, коро тот!
Ничек итсен, китте бабай
Алтын балык катына,

Тагын аны әкрен генә
Үз янына чакыра.
Чыкты балык жар читенә.
Суу әз генә болганды.
„Нәй хал, бабай, нәй киряк?“ диб
Ул бабайдан сорады.
„Эй кадерле алтын балык,
Жөзөм синнян ояла:
Безгяк карчык бер жорт сорой,
Зимнянкябез ыуала“...
—Бар кайт өйгя, жакшы бабай,
Бирем сезгя жакшы жорт;
Тик онотма, жакшы бабай,
Бәлебкеня жыйнак тот.
Бабай, аңар башырды да
Өйгя таба боролды
Ул арада кодрят белян
Бер олo жорт королды.
Кюзе төштө карт бабайнын
Зимнянкясе урнына:
„Бу ней хал бу, ней тамаша,
Бик жакшы жорт кюреня!?..“
Зур өй, алты почмаклы,
Жяшел калай тюбяле,
Матургына өй-алды,
Сигез-тугыз тярязлә;
Матур урыс-кабкасы,
Ие китярлек амбарлар,

Тюбя нäрат тактасы...
Äлля каян алганнар!
Кодряд белян булган жортка
Бабай куркыб керядер.
Усал карчык тярязядян
Аны тизюк кюрядер.
„Кермя, кермя бу öс белян,
Сал, белемсез, туныңны!
Сал кюлмягеӊ мя жаңаны;—
Жыу жакшылаб кулыңны!"
Шулай карчык тамак жара
Чыгыб бачкыч тöбöня.
Ӱзе дя ул бютян булган—
Жаңа кейгян öстöня.
Бабай öстöн чишенде дя,
Жаңа кейем кейенде.
Балык биргян жаңа жортка
Чын кюңелдян сöйöндö.

III.

Беряр атна тулды микян,
Карчык тагы котора—
Куркак картнын котон алыб,
Тамак жарыб кычкыра:
„Бар балыкка äйт тизеряк—
Бу сюземне кылсын тиз!—
Минут тормой итсен мине
Первой гильдии кюпис!"

Бабай ауыз ачкан ыйы
Ангар бер сюз айтергя,
Карчык тöртöб чыгаргачтын,
Эссе булды китяргя.
Килде бабай жар буйына
Бик оялыб балыктан.
Балык аны кюреў белян,
Ўзюк сыудан калыккан.
— „Ней айтерсенг, жакшы бабай?
Ошады мы жортогыз?
Уз уйымча арыу булыр,
Тик бик белеб тотогыз“.
— Эй кадерле алтын балык,
Мин бик шöкöр бар малга,
Тик туйымсыз карчык кына
Карый бездян байларга:
Мужик булыб тормойым, дей,
Кюпис итмяс микян дей...
Мин жугыйса килмяс эйем,
Нишлейем сунг, бик ярлей“.
— „Жарар, бабай, можно булыр,
Тынычланыб кайт öйгя“.
Карчык шундук кюпис булды,
Бабай öйгя кайтыуга.
Киля бабай öйгя таба.
Кюз кютяреб караса,
Кюпис жорто кюз алдында—
Меня тагы тамаша!

Оло кирбеч пулӑтлар,
Вывескалы ӑмбарлар,
Амбӑр сайын зур жӧкляр
Жӧктя тӧрлӧ тауарлар.
Карчык жӧрӧй болганыб
Жепяк зонтик таяпыб
Прикащикляр жазалар,
Тӑуӑр сӑпаб ӑлалар.
Карчыгына жакын килгяч,
Салды бабай кӑртусын.
„Жя, карчыгым, шӧкӧр инде...
Алла гумреӊ ӑрттырсын,
Жаӊӑ тормош котло булсын!“—
Шулӑй бабай котлады.
Карчык, анар карамыйчы,
Алга ляп-лӧр атлады.
Калды бабай башын селкеб
Олосымак карчыкка
Аннан ӑры бер амбарда
Он тӧйӧште кабчыкка.
Эшляб аргач, керде бабай
Жаӊа пулат эченя.
Чяй эчкячтен, утын кертте
Кухнясенен пиченя.
Ул кухнядя ике катын
Аш пешереб жӧрӧйляр.
Иске кейгян ике татар
Ишек-ӑлды кӧрӧйляр.

Карчык ӱзе бер эш тотмой,
Беялей дя бяйлямей.
Жорт эчендя ней беткянне,
Ней кирякне шяйлямей.
Обед сайын бстялендя
Оч-дюрт тӧрлӧ пирямян;
Атна кӧннӧ, бяйрям кӧннӧ
Булсын ангар гел пилмян.
Обед итеб бетергенче
Эчя тӧрлӧ аракы;
Ашаб-эчеб ауырайгач,
Бик жарата ул жоко.

IV.

Беряр айлаб ӱтте микян,
Карчык картка дяштеря.
Бабай килеб кереӱ белян
Ангар былай кычкыра:
Тиз барыб кайт балыгыка,
Айт син ангар меня ней:
Инде мине дворян итсен,—
Кюпис булыб туйдым!—дей.
Бабай тагы башын кашый...
Карчык исен китеря:
Зимнянкядя торган чагын
Ул исеня тӧшӧря.
Ней эшлярсен анын белян?..
Китте бабай тагынук.

Акрен геня киля жарга,
Кото чыккан куян кюк.

Дяш р-дяшмяс тора жарда
Дингез ныгук тулкынный,
Кычкырырга курка бабай,
Жөрякяйе сулкылдый.

Бер-аз торгач, чыкты балык
Теке жарнын читеня.
Айтер сюзен айтте бабай.
(Кызыл төштө битеня).

— „Эй кадерле алтын балык
Карый кюрмя битемя...
Теге карчык тагы туймый;
Дворян ит диб ўтеця.

— „Можно булыр“, диде балык:
„Тынычланыб кайт өйгя“.
Тагы бик зур кодрят булды
Бабай өйгя кайтыуга.

Жакын киля ўз жортона...
Ней кюз белян кюрерсен!..
Тагы бютян жортлар тора,—
Төш кюрям диб белерсен!

Ике катлы таш пулатный
Жанында сад-бакчасы;
Сад эчендя тагы бер жорт—
Бу буладыр мунчасы.

Ишек алды-зур болон кюк;
Бӧтӧнняй таш жяйдергян;
Кäретниктя пар äт тора
Каретага жигелгян.

Паралныйдан чыкты карчык.
„Подавай!“—диб кычкыра.
Бейей-бейей киля пар ат,
Икесе дя пышкыра.

Читтян гөня караб тора
Ӱз карчыгын карт бабай.
Каретага ишек ача
Сертук кейгян бер малай.

Карчык кереб утырды да
„Ну, пошел!“—диб кычкырды.
Жирсяб торгäн жяш айгырлар
Очкан кӧш кюк ычкынды.

Шаклар катыб тора бабай
Карчык дворян булганга;
Исе китя, уйы житмей
Алтын балык кылганга.

Тора беля усал карчык,
Дворян заты дирерсең:
Ашый-эчя, кӧндя сыйда,
Бäйрям бар диб белерсең.

V.

Ӱтте шулай жарты жыллаб
Карчык нейляр кылынмый.

Дворян булыу начар тея,—
Тагы тормош талымный.

„Мына бердя бер кённярдя
Чыкты карчык кухняга.
Бабай гырлаб жоклаб жата
Пич артында бюлмядя.

„Тор ўнярсез, белемсез карт!
Нишляб жоклаб жатасынг?
Бар барыб кайт балыгынга!..
Пик багытсыз жоклойсынг?

Айт балыкка, кеняз итсен—
Туйдым дворян булыудан.
Бар, бар тизряк, кейен őстőнг,
Тиз тőш жаткан урнынгнан!

Ынгыраша мескен-бабай:
Бил кузгалган эштян сунг;
Начылый гына тőшőб кея
Жыртык жорток иске тун.

Китя балык жанына ул;
Бу жул да бик оялa.
Каты жилляр исеб тора,—
Дингез тагы кузгала.

Кыяр-кыймас, бик оялыб,
Тагы дяшя балыкка
Ўзе, мескен, дер-дер киля:
Бигюк туймый саулыкка.

Чыкты балык жар буйына,
Бабай сюзен тыңнады.
„Можно булыр!“ диде дя, ул
Тагы сыуга ыргыды.
Шул минутта усал карчык
Тизюк кенязди булды.
Жорто-жире тагы бютян,
Ар-бер жире буяулы.
Дворян белян кеняз заты
Бер тöрлöряк торалар.
Тик кенязгя бирелядер
Тöрлö-тöрлö мидаллар.
Карчыкнында кюкрягендя
Алля нейдей мидаллар.
Тышка кейеб чыккан чакта,
Жалт-жолт итеб торалар.

VI.

Мидаллар да бик туйдырды
Беряр жылдан карчыкны
Тагы картка жомош таба,
Комачаулый балыкны:
Бар барыб кайт балыгыңа! —
Калдык табкыр булдыр дыр —
Кеняз булыу начар икян,
Падша булыу арыу дыр.
Куйсын мине падша итеб
Бер падшалык жиреня!

Куймый икян, ўзем барым
Оло дингез жарына.
Мин барыуны кӧтӧб жатса,
Кюрсятермен кюзеня:
Аня дӧмбӧ, ышанмаса
Минем айткян сюземя!..

Бу жул бабай тюзмейенче
Карчыгына жабышты,
Куркыуын да белмейенче,
Учетляргя тырышты:

„Карчык, карчык! Ник алай син
Ул балыкка каныктың,
Ничек иткян изгелеген
Алай бик тиз оноттың?

V.

Мужик ыйың, кюпис итте;
Аннан менден дворянга
Бӧтӧн калык исе китте
Кинят кеняз булганга.

Карчык картка боролдо да
Сяйер сенеб карады.
Шунда торган лакейляргя
Кыскагына бойордо:

„Чыгарыгыз тиле картны,
Тӧйгялягез жилкясен,—
Мыннан ары кушкан эшне
Карышмыйчын эшлясен!“

Картны чырмаб алдылар да,
Тӧйгялябюк алдылар,
Аннан ары тоттолар да
Ӧйалдыннан аттылар.

Барыб тӧштӧ мескен-бабай,
Башы ташка чяк итте.
Башыннан да, барионнан да
Гярляб кара кан китте.

Начылый гына тордо мескен,
Айкан-чайкан тилпеня.
Мыны кюреб, кӧля карчык—
Бар гяўдясе селкеня.

Аннан ары тагы куша
Сыу жарына барырга.
Китте бабай жылый-жылый
Битляренняп кан ага.

Ничек ғиряк алайгына
Килеб жарга утырды;
Бик оялыб, қыяр-кыймас,
Балыкайын чакырды.

Чыкты сыудан алтын балык
Дингез кинят шаулады.
„Ник жылыйсың син, бабай?“ диб
Балык аннан сорады.

„Эй қадерле алтын балык,
Тагы ней хӓл итейем?..
Тынгы бирмей усал карчык,
Ник мин ўлеб китмейем?..

Бик намыссыз карчык булды,
Аман кюзе туймый шул
Падша итмяссең ме аны—
Меня нястя сорой ул!..“

Дингез тагы шаулаб китте,
Артык жил дя жук ыйы.
Алтын балык сыуга чумды,
Бик болганды жар буйы.

Меня тагы чыкты балык;
Зур сөйөнөч бабайга.
Можно булыр диде дя ул
Тизюк чумды тугайга.
Кайта бабай өйгя таба;
Эче пошa, көйөня.
Бара торгач кюзляреня
Бик шяб кала кюреня!
Аня самый уртасында
Бейек пулат кюренде.
Бабай мыны кюнгеленнян
Падша жорто дыр диде.
Керде бабай урам белян
Киля падша жортона...
Мылтык тоткан бер жяш салдат
Мына мыңар тотона:

VI.

Син нейдей карт, ник килясең?
Бар тизеряк кит, картлач!
Обедтан суң падша чыгар,—
Жакын килмя, жырак кач!
Сызды бабай, кото чыкты,
Кул-аягы каушады.
Инде кая тором суң диб
Эче поша башлады.
Ул арада теге салдат
Аңар тагы кычкыра:

„Бабай бабай!.. Эй карт бабай!..
Падша сине чакыра!..
Куркыб китте тагы бабай...
Падша нейгя чакырсын?
Тормошоӊ ней... Бер айыбсыз
Ӧтӧрмянгя жатырсыӊ...
Кинят бабай кюзен салды
Жугарыгы тярязгя:
Падша-карчык бармак селкей
Бер карткына кенязгя.
Эй балыкнын кодрятляре—
Тӧш кюрям диб уйларсыӊ?..
Нужа карчык падша булгач,
Ничек шаклар катмассыӊ!..
Жалт-жолт киля асыл бюрек
Ӓбей-падша башында;
Ут кюк жана мидаллары
Калкыугына тюшендя.
Министырлар, сапатлар да
Бар да шунда жыйылган.
Ӧй жанында салдатлар да
Жул-жул тезеб куйылган.
Бабай бара ӓштӧр-ӧштӧр
Бер ӓписяр артыннан.
Жак жагына карамый да
Оялыудан, куркыудан.
Ул ӓписяр карт бабайны
Алыб керде кухнягя.

Бер поварга приказ берде
Ашарыча бирергя.
Тамак туйды карт бабайнын,—
Позар бик нык сыйлады:
Ӧч пирямян аш утыртты,
Тик эчемнек куймады;
Ашагачтын кюрсяттеляр
Ул торасы бюлмяне
Мындый матур чиста бюлмя
Жук бабайнын кюргяне.
Кӧнняр ӱтеб, айлар тула...
Эш бабайнын бик жайлы
Карчык аны шелтялямей,
Тамак кӧндя бик сыйлы.
Карчык падша булганнан суң,
Ӱтте гумер дюрт-биш ай.
Шул бер кюргяч кюрмей äле
Ӱз карчыгын карт бабай.
Бик дӧрӧсӧн äйткян чакта,
Кюрясе дя бик килмей.
Ӧйдян чыгыб жӧрмягячтен
Падша хален ул белмей.

VII.

Меня бердя бер кӧннярдя,
Тыныч кына торганда,
Киля беряӱ карт бабайга,
Кич карангы булганда.

„Бабай, бабай! Бар тизеряк,
Сине падша чакыра!..“
Öскя салкын сыу сибкян кюк,
Бабай урнынан тора.
Алыб китте теге кеше
Карт бабайны падшага
Бара торгач бер ишектян
Падша чыкты карышыга.
Бюрек дисяң, бюрек тöгöл,
Алля нястя башында;
Жем-жем итя кыйбатлы таш
Жöзöгöнен кашында.
Тюшен киреб тора карчык,
Уклау жоткан дирерсең.
Кыйланыуын кюрмяс öчöн
Узең акча бирерсең.
Аңар килеб житеў белян,
Бабай тизюк башырды
Карчык аңар туры караб
Меня ней эш табшырды:
„Бар барыб кайт балыгыңа,
Тагы бер эш эшлясен.
Жир падшасы булыб туйдым,—
Сыу падшасы тиз итсен.
Оло диңгез уртасында
Корым падша жортлары
Читтян килгян кунакларга
Балкыб торор утлары.

Алтын балык ўзе минга
Кызмят итяр шул чакта
Падшасына илче булыб
Гумер итяр жомакта“...

Сюз айтергя кыймыйынчы,
Китте бабай балыкка
Дингез каты шаулаганы
Эшетеля колакка.

Килде бабай сыу жарына.
Ойдян бейек тулкыннар;
Жилляр жиллей, болот киля,—
Булыр каты жангырлар.

Алля ничя дяште бабай,
Алтын балык эштетмей:
Жангыр жауа, жяшен жяшней,
Жилне бердя киметмей.

Жарты сагят бик ўткяндер,
Бабай мында килгянгя.
Алля балык чыкмый микян
Сыулар жарга менгянгя?..

Инде ней хял итейем диб
Бабай-мескен бик поша.
Шул кӧйӧнчӧ ӧйгя кайтса,
Алля нишлятер падша.

Меня жилляр басылалар,
Тулкыннар да тарала.

Сылар казер äкрен шаулый,
Ди гез öстöка рала.

Тора-бара бöтöнняюк
Оло диӊгез басыла
Алтын балык чыгыб киля,
Бабай тизюк аӊ сала.

VIII.

—„Бик арыумы, жакшы бабай!
Äлля тагы жомош бар?
Äйт тизеряк, жакшы бабай,—
Бик ашыгам, арам тар“.

„Эй кадерле алтын балык,
Бик кызарам, оялам.
Ник ӱлмейем икян суӊ мин,—
Карчык беляв саргаям.

Падша кöйö туймый äле
Шундый рахят кöнöня:
Сыу падшасы итмяс ме диб
Инде сиӊа ӱтеня...

Тик ӱзеӊне, алтын балык,
Зур санаты итям дей...
Бу ней тöрлö туймас кеше?..
Уйлаб уйым житялмей!..“

Балык кöлöб, башын чайкый.
Диӊгез сыуы болганчык...

„Сау бул, бабай, ка ойонгя,
Туймый агай ул карчык!..“

Шулай дигяч, алтын балык
Сыуга тизюк ыргылды.
Кинят каты кюк кюкряде,
Бабай куркыб жыгылды.

Китте бабай ойгя таба
Ӱзе курка карчыктан
Ӑкрен геня киля, мескен,
Кул аягы талчыккан.

Озак кына килде бабай,
Кюренмейля каласы?..
Тőн дя житте, каб-карангы,
Кая таба барасы?..

Бара торгач кюзе тőшто
Иске зимнянкясеня!
Усал карчык жылаб тора—
Тőшкян икян исеня!..

Ней айтергя белмейенче,
Бара бабай алгарак.
Бара торгач кюзе тőшся—
Жирдя жарык тагарак!..

Куян жорто.

Көзгя таба бер куян
Уйлый бер жорт салырга.
Меня киля бер айыу
Шушы куян жанына.
— Ней эшлейсең, кылый кюз?
— Ой саламын, айыу дус:
Кышкы көнняр житяляр
Туңа башлар жилкяляр.
— Жарар, салсаң салырсың,
Тик оло сал өйөңгяе:
Миңа да урын булмаса,
Турылармын кюзеңне.
Киткяч айыу-бабабыз,
Киля бюре абабыз.
— Ней эшлейсең, кылый кюз?
— Ой саламын, бюре-дус.
Жарар, салсаң салырсың
Тик белеб кыл эшеңне.—
Мин сыярлык булмаса,
Кыскартырмын тешеңне.
Китте бюре бабабыз,
Киля төлкө-тутабыз.
— Ней эшлейсең, куян дус?
— Ой саламын. төлкө дус.
— Ай бик рахмят, куян дус...
Кюрешейек, кулың суз.

Арыумы, бик, исянме?
Балаларың ўсяме?
Карчык кая, кюренмей,
Беряр жары киттеме?
Уя кабкынга кысылды,
Балаларым атылды.
Тöлкö тютей киткячтен,
Бер тыч канда жöгöря,
Куян белян кюрешеб,
Меня пейляр чöмгöря:
— Арыу мы бик, ак-бабай!
Ней эшляргя келейсең?
Öй саламын, тычкан-дус
Ўзең ниш ляб жöрöйсең?
Эшем таман, ак-бабай,
Öйöм тузган, бик начар.
Кыш торорга жарамас:
Сыуык булыр, жя басар.
— Эй тычкан дус, кайгырма,
Кил минем öй астына:
Татыу булсак сыярбыз,
Бергя ризык жыярбыз.

II.

Меня житте сыуык кыш.
Буран уйный сызгырыб.
Куян жата жаңа öйдя,
Ут алдында кызыныб.

Мына киля теге айыу,
Ишек кага бик кыйыу:
—Ач ишегең, кылый-кюз! .
—Ачам, ачам айыу-дус.
Айыу алга барды да,
Ут алдына жатты да.
Куян чикте арткарак,
Пичтяр бер-аз жангарак.
Меня киля бюре-дус,
Ишек кага: „шак-шак-шак!“
—Ач ишегең, кылый кюз!
Ник бикляндең син куркак?
— Килче, керче бюре-дус.
Жакшы мында жылыда.
Барыбыз да сыярбыз,—
Айыу-бабай да мында.
Жатты бюре сузылыб,
Айыу беляң жяняшя.
Беряр сагят ӱткячтен,
Тӧлкӧ-тютей дя дяшя:
— Куян-дусым, роксят ме?
— Роксят, тютей! Исяңме?..
Килче бире утырчы,
Ут алдында жылынчы.
Ӱтте тӧлкӧ алгарак,
Бюре-дуска табарак.
Жорт хужасы тагы да
Чикте бер аз жангарак.

III.

Кöйсöз эше куянның...
Нейляр булыр, ней жазар...
Ней хäл итсен, тюзяр шул,—
Теймясяляр дя жарар.

Караб тора бер тычкан
Пич астыннäн, жарыктан..
Кюреб нейляр булганны,
Эжялляде куянны.

Пич алдына менде дя,
Эссе кюмер алды да,
Жоклаб жаткан айыуның
Корсагына салды да!

Корсак пещя башлагач,
Айыу сикереб тордо да
Шырый-шырый кычкырыб,
Öйдян чыгыб сузды да!

Бюре белян тöлкö дя
Куркыб чыгыб чабтылар.
Куян белян шул тычкан
Ут алдына жаттылар.

Äле булса ул дуслар
Тыныч гумер итяляр.
Куркыб чабкан кейекляр
Öйгя кермей ÿтяляр.

Эй кодача! Эшеттек
Искеняйең китясе

Оч-дюртс сăгят эчендя
Бӧтӧн жортог бетясе.

Мыгар чаклы, бик шӧкӧр,
Ут халлярен белмядек
Шӧкӧр уткян гумергя
Зур нужалык кюрмядек.

АТ.

Сига хужам, инялямен
Бик интегеб, тилмереб:
Тамагымны жакшы туйдыр,
Багытында эчереб.

Ӧйрят мине чыбыркысыз
Тямне, татлы сюз белян,
Сыйпа мине, сӧй жилкямнян
Кара жакшы кюз белян.

Жул жӧргяндя кыума мине
Кычкырыныб, суккалаб;
Ауызымны ауырттырма,
Кирякмяскя тарткалаб.

Жӧгӧм ауыр булган чакта,
Таудан тӧшӧб меня кюр;
Аркалыгым бейек булса,
Аны тизюк чишя кюр.

Аксаклаган чагым булса,
Тотоб кара аягым:
Дагаларым кысмый микян,
Жарылмыймы тоягым.

Таман булсын, көйлө булсын
Кеяр камыт-жөгяпем.
Аргач жатыб жал итярге
Чиста булсын идянем.

Кышын-жяйен эчерт мине
Тяўлегеня өч табкыр,
Чирле чагым була икян,
Мал докторын тиз чакыр.

Мине шулай кастярляўең
Бик зур пайда китерер:
Кюб эшлярең тиз эшлянер,
Тормошоңны кютярер.

Кязя

Кязя кергян бакчага
Кыяр-фялян ашарга.
Таяк тотоб чыксалар,
Ӑзер чыгыб качарга.

Бу жул, нейдян булгандыр,
Кязябез дя жангышкан;

Кошe чыгыб жикергяч,
Куркыуыннан адашкан.

„Кязя! Шилмы, мякаржя!
Жöзö кара мал икян:
Харяб иткян, бакчаны—
Тютяллярне кöл иткян!..

Кязя, жауыз, ачарбак!
Кергян жиренг жуйдынг мы?..
Эй тотсамчы, кояштыр,
Öзяр эйем муйныгны!“...

Ул арада хужабыз
Жакыннаша кязягя,
Ачуланыб, сюгенеб,
Балта белян кизяня.

Дöнья кюргян кязягя
Бигюк куркыу килешмей.
Таяк белян чыбыкка
Кязя малы бирешмей.

Балта кюргяч, алайда,
Тöйöн тöштö кязейгя:
Балта тейеб киселся,
Ничек кайтыр ул öйгя?..

Кязя жакшук шикляня,
Арле-бирле чабкалый,
Кюзен-башын тасрайтыб,
Кычкырыб та куйгалый.

„Кязя, шилмы, сабакы!
Балтасы да теймей бит!..
Эй тотарга жауызны,—
Бер кеше дя килмей бит“...

Мына кинят кешебез
Абынцы да, жыгылды:
Ул арада кязябез
Уз жулыннан ыргылды.

„Ай собака, ай шайтан,
Аня жулы кай-икян!
Кязя, жауыз, ачарбак!
Тагы кермяссен микян?“...

Тычкан.

Жöрöй торгач бер тычкан
Керде читлек эченя:
Май куйганнар тябегя,
Чыдар халь жук исеня.

Сикреб менде чябегя,
Жалангалаб, жалманыб,—
Кинят тябе шарт! итте
Тычкан тöштö каблаиыб.

Онотолдо май исе:
Жул эзлей ул чыгарга,
Зур хатярдян котолоб,
Ӱз иленя сызарга.
Килде тизюк ишеккя—
Ишек тыштан биклянгян!
Тӧртӧб-тӧртӧб караса,
Ачылмаслык иблянгян.
Чабыб килде почмакка,
Борнон тыга тишеккя:
Барон сыя, баш сыймый..
Китте тагын ишеккя.
Дер-дер киля месҟенкяй,
Кото-коно калмады:
Чыгарга жул табылмый,—
Эляккянен агнады.
Инде ней халь итясе?..
Кеше кюрся нишлятер?..
Нишлятясе билгеле—
Мячесеня тешлятер...

Оло тилеляр.

Ике тиле киляляр,
Кюктя болот кюряляр.
„Жаңгыр киля бит, Бячлей!“
Бячлейгя айтя Темяпей.

— Жук, боз булыр: сизямсең,
Ак болотно кюрямсең?
Кызгылт болот дауылга,
Кара болот жаңгырга...

Бячлей беляв Темяшей
Ареблящя башлады.
Мыңар тиле Бячлейе
Бер тöртöб тя ташлады.

Меня кызыб киттеляр,
Сугышыргук життеляр,
Берсе берсен этяляр,
Кюкряклярге тöртяляр.

Кипят Темяш Бячлейгя
Бик ныгытыб бер тийте.
Бячлей, эчеп тотто да,
Ауган агач кюк китте.

Тизюк сикреб тордо да,
Очоб куныб ордо да!
Кычкыралар, дыулыйлар,
Эт шикеллюк ыулыйлар.

Ей тилеляр, тилеляр! —
Ник усал, сез алаюк? —
Болот кюбтян торалды, —
Жаңгыр да жук, боз да жук.

Уйсыз дунггыз.

(По Крылову).

Оло гына бер дунгыз
Бара басыу тюреня.
Бара торгач, кюзеня
Бер карт имян кюреня.
Бу буладыр кӧз кӧнӧ,
Ӑкялейляр житкяндя,
Сентябрнен башында,
Басыу эше беткяндя.
Житте дунгыз имянгя.
Анекяйем, ӑкялей!!—
Имян тӧбӧ жаб-жакты,
Аман ӑз-мяз тӧшкялей!
Жара дунгыз чикейне,
Кытырт-кытырт китеря.
Жилпуч чаклы колаклар
Кабкан сайын сикеря.
Корсак тула башлагач,
Ашауыннан туктады,
Кюлягяга барды да,
Бер-аз жатыб жоклады.
Беряр сагят ӳткячтен,
Жокосоннан тордо бу,
Кирелгяляб, сузылыб,
Эшне былай бордо бу:

Карын ачыб житмягач,
Тамыр казый башлады.
Ӧч-дюрт минут эчендя
Кюб жир сӧрӧб ташлады.
Ул эшлягян арада,
Карга кунган имянгя.
Тора торгач, кюз салды
Мырык-мырык килгянгя.
„Ник казыйсың тамырны?
Короторсоң имянне!
Белмейсең дер акыры
Ашың каян килгянне.“—
Карга мынгар шулай дей,
Бӧтӧн кырны сасытыб
Дунгыз аңар былый дей,
Мыскыл итеб, жарсытыб:
„Эй карга дус, карга дус,
Жукка мында килгянең.
Ӑкялейляр бар чакта,
Корса корсон имянең.
Ней файда бар имяннян?
Мине тӧшӧ симертя.
Артыгырык ашасаң,
Анысы да кикертя“...
Уйсыз дунгыз аңнамый
Ашамныксыз калырны:
Карга сюзен тыңнамый,
Аман казый тамырны.

Эттян сӧяк артмас.

Сарбай белян Актырнак
Кочаклашыб жаталар;
Берсен берсен уйнашыб,
Тешляб-тешляб тарталар.

„Ай, дус икян бу этляр,—
Ничек кеня уйныйлар“,
Узган барган кешеляр
Бар да шулай уйлыйлар.

Кюрде этлярне бер малай,
Жакын киля башлады,
Сызгырды да быларга
Ит сӧяге ташлады.

Этляр сикреб тордолар,
Кабаланыб чабтылар,
Икесе дя бер жулы
Ул сӧякне кабтылар.

Меня китте тартышыу;
Дуслар ырлый башлады.
Актырнагы Сарбайны
Бер тешляб тя ташлады.

Сӧяк тештян ычкынды,—
Меня китте талашыу.
Бар этлярне кузгатты
Кот чыгаргыч ырлашыу.

Килде башлаб Актабан;
Араларга тырыша.
Килеб житте Шарик тя,
Актабанга сырыша.

Килгян эйе Муйнак та
Сугышырга жасаныб,
Тик сёякня кюз тöшкяч,
Кинят китте тукталыб.

Ул, сёякне кабты да,
Сызды тизряк öйöня.
Асат табкан табышка
Чын кюнелдян сöйöня.

Ул арэда теге этляр
Ченчей канга быттылар.
Бар да, халдян тайгачтын,
Öйгя кайтыб жаттылар.

Ўкеняляр ўзляре
Жукка сугыш корганга;
Урамга да чыкмыйлар,
Баш ауыртыб торганга.

Бер-ике кöн ўткячтен,
Сарбай белян Актырнак
Тагын öйдян чыктылар,
Жамансылаб, абтыраб.

Äкрен-äкрен килделяр
Бер берсенен жанына,

Исяншяляр, сыйыныб
Бер берсенен санына.

Тагы жнргя жаттылар—
Онотолды талашыу:
Йт сöяге табкынчы,
Дуслар тагы бик татыу.

Сугыш халляре.

I.

Кюрем микян тыныч тормош,—
Кайчан бетяр бу сугыш?..
Ней жяш койоу, ней кан тюгеў,
Ауырайа бит сулыш.

Улгяндя дя онотмамын
Питеремнен киткянен,
Калдык табкыр, жылый-жылый,
Алашаны жиккянен

Öйгя кергяч жакын килде
Бишектяге балага:
Сыурыб-сыурыб ўбте мескен,
Кюзляренниян жяш ага.

Чяйляр эчкяч äзерляиде
Озон жулга чыгарга.
Эй ауыр халь... Мöнким тöгöл
Жыламыйчы чыдарга.

Ўкреб-ўкреб жылады шул
Öйдян чыгыб киткяндя;
Урам ингняб калык киля,
Зур ачыкка житкяндя.

Бöтöн урам жярминкя кюк
Шау килялар, урман кюк
Ауыр халляр, ай бик ауыр,—
Жыламаган кешюк жук.

Салдатларнын кайсылары
Интегешеб жырлыйлар,
Озатыучы катын кызлар
Кеткелдяшеб жылыйлар.

Шул чагында булган халне
Читен рятляб äйтеўе...
Ўлек кюмеў ничек була,
Шулай салдат китеўе.

Сугыш бетеб, исяннектя
Кюрем микян улымны,
Äлля кюрмей ўлярем ме,—
Кöн дя кöтям ўлемне?..

II.

Почта жаны шыгырым,—
Ачмый озак тоталар;

Кай-бер кеше кӧтмӧйчен,
Ӧйгя таба кайталар.

Питеремнян жазыу жук.
Ӧч-дюрт айлаб булды инде.
Иванымнан аннан суң
Ике жазыу килде инде.

Бу почтада килмяся,
Харяб эшем, бик кӧйсӧз;
Ӱзем кана гел жазам—
Атна сайын ӧзӧмсӧз.

Ӱлмягяйе диб куркам,
Котом чыга, жаным жук.
Аня Симун Игнаты
Ӱлгян икян былтырук.

Плингя тӧшся тагынук
Бик:юк айбят эш тӧгӧл:
Жир казытыб, ач тотоб,
Интектереб бетерер.

— Алясандыр Кючтянтич,
Жук мы жазыу Питердян?
Бу жул почта зур икян,
Бик кюб нястя китергян.

— Сезгя жазыу бар, жингей,
Тик белмейем кемнян дер
— Ходай ӧчӧн карачы,
Питеремнян килгяндер!..

III.

Эй сӧйӧклӧ Äтей, Äней!
Меня тагы хат салам.
Сездя, рахмят, онотмойсоз,—
Атна сайын хат алам.
Син дя, жан цей кюргян кушым,
Арыу гына торамсың?
Кайгы-касрят картайта мы,—
Бик зур карчык буламсык?
Син дя, балам, матур улым,
Ней халь белян торасың?
Укыуыңны жаратамсың,
Ней уйыннар корасың?
Äтей, Äней, жамагатым,
Минем ӧчӧн кӧймягез.
Мине сорагаННарга да
Жакшы хабяр сӧйлягез.
Аста салам булган чакта,
Гормош рахят теядер,
Уйын-кӧлкӧ сюзляр белян
Гумер бик тиз ӳтядер.
Тамак шӧкӧр, бик тук äле,
Ӧстӧбӧз дя бик бӧтӧи,
Тик сӧптан чыксаң гына
Тиря жаклар гел тӧтӧн.
Ул тӧтӧн дя, бэр кюнеккяч,
Жӧряклярне жилкетмей;

Тӧтӧн тӧгӧл, пушкысм да
Беряўне дя куркытмый.
Ӓтей, Ӓней, жамагатым,
Кӧйӧнмяўгез, тюзегез:
Ач, жалангач булмассыздыр,
Сау булсагыз ўзегез.
Ӓйтер сюзем бетте бугай,
Жя, сау булыб торогоз!
Сездя, бигюк озакламый,
Хатыгызны салыгыз.
Бик кюбтян кюб сялям ӓйтям
Бабай беляп Ӓбейгя,
Ӓрняштяге кодаларга,
Аудый жырак—тютейгя.
Арам тыгыз, барына да
Атаб сялям ӓйтергя,—
Бик кюбтян кюб сялям дигез
Сораганга ӓр кемгя.

———

Без сугышка чыккан чакта,
Озаттылар тюряляр.
Ата-баба кюрмягянне
Безнең башлар кюряляр.
Висла суын чыккан чакта,
Бик кюбебез чирляде.
Бик кюб салдат кайтмыйынчы
Жат иллярдя жирлянде.

Без китярбез иртягя,
Кабчык салыб жилкягя;
Китмяс әйек иртягя,
Дошман төя тенкягя.

Ауыр шинил ингемдя,
Кара кайыш билемдя.
Исян кайтыб тором микян
Тыуыб ўскян илемдя?..

Шинил баса ингемне
Кайыш кыса билемне.
Кара чячем агарса да
Оңотмамын илемне.

IV.

Эй сөйөклө Иван улым!
Без дя синга жазабыз
Көн торможон, ил хабярен,
Кючтинич тя салабыз.

Аз булса да кюб ит инде—
Тугыз кадак сөхаре.
Жарты потук саласы ыйык,
Алмады бит почтаре.

Жортта халляр имен әле,
Бик исян, сау жөрөйбез.
Синең исяннегеңне дя
Бер Алладан телейбез.

Алашаны кюбтян тӧгӧл
Мобильзовайт иттеляр.
Бездян алган атлар беляп
Казанга диб киттеляр.

Айгырыбыз бик кӧр жӧрӧй,
Тамагын нык туйдырам.
Бурлар алыб китмясен диб
Кӧн дя бикляб кундырам.

Оло сыйыр бызаулады.
Бу жул бикяч китерде
Жяш сыйыр да ауыр жӧрӧй,—
Инде жилем тутырды.

Нособие киля тора
Ике-ӧч айга бер табкыр.
Алля нишляб, шул кӧйӧ дя,
Кеся жагы таб-такыр.

Такыр булмый ничек булсын,—
Ар бер нястя бик кыйбат:
Жӧз меңнян дя артык хазер
Начар сыйыр, начар ат.

Мең ӧлӧш артты бар нястя дя
Элекеге бяядян:
Утыз меңняб алалар бит
Ӧч тяңкялек кязядян!

Бер сдерке ун биш тяңкя,
Сиксян тяңкя агач кӧряк.

Кыйбат булса булсын ыйы,
Ул да чыга бик сейряк.

Анаг шырны бетя дися,
Куркыб китям кай чакта:
Жӧздян артык туныйлар бит
Спекулянтлар бер кабка!

Кюбтян тӧгӧл Кулаковны
Шикяр белян тоттолар,
Ун меӊ тянкя тюлямягяч,
Ӧтӧрмянгя жабтылар.

Айдя жатсын, бигряк таман,
Бюрткян эйе борчагы.
Аллы-туклы бер аз жатса,
Шигяр оло корсагы.

Шулай, улым, кеше хакы
Ичтя файда китермей.
Гадел тормош, эшляб туйыныу
Жакшы исемне бетермей.

Жазар сюзляр бетте бугай,
Жя, сау булыб тор, балам!
Алга таба-анаг сюзе,
Ул ӓйткянне мин жазам:

„Балакайым, арыу жӧрӧ,
Ӓр бер турда бул гадел,
Гаделлекне саклау ӧчӧн
Жан бирергя бул ӓзер“.

Кояш чыгар әйләнеб,
Алма-агачка бәйләнеб;
Жазган булса, кайтырсың,
Сугыш жирен әйләнеб.

Дошман башы жәнчелсен,
Эштигеня чәнчелсен;
Сугыш берюк тукталсын,
Балакайым тиз кайтсын.

3-я Государственная Типография.